ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422723,Республика Татарстан,Высокогорский район,
с.Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

тел./факс 8(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**19 май 2020 ел** **№ 21**

**Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитетының 25.09.2018 ел, № 6 карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, «Федераль мәгълүмати адреслы система» һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 26 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитетының 2018 елның 25 сентябрендәге 6 номерлы карары (01.03.2019 ел, 34 нче номерлы карар редакциясендә) белән расланган Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә адресларны бирү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында:

1) 1.5 пунктында:

а) 3 абзацта "планлаштыру структурасы элементы (кирәк булганда), урам-юл челтәре элементы" сүзләрен «урам-юл челтәре элементы һәм (яисә) планлаштыру структурасы элементының (кирәк булганда) атамасы " сүзләренә алмаштырырга)»;

б) 5 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«адресация объекты - капиталь төзелеш объекты, җир кишәрлеге яки Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән адресация объектлары исемлеге белән каралган башка объект;».

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Алан-Бәксәр авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе З.Р.Гарифуллина